| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **16.09.2019 ел** | **№ 20** |

**Кече Мәми авылы**

**Кече Мәми авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә Кече Мәми авыл җирлеге Советы **КАРАР** кабул итте:

1. Кече Мәми авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Кече Мәми авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2020 елда Кече Мәми авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- коены ремонтлау, төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:*

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм төзекләндерү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм Кайбыч муниципаль районы Кече

Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://mmemin-kaybici.tatarstan.ru..

3. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы** **Е.Н.Алексеева**